# Исәнмесез, укучылар.
# Хәерле иртә!
# Егерменче май.



**I. Прочитайте текст. Определите какие из приведенных утверждений 1-7 соответствуют содержанию текста (а) – текстка туры килә), какие не соответствуют (ә) – текстка туры килми).**

- Татарстанның табигате бик матур, бай, серле һәм төрле. Калын зур урманнар да, тигез далалар да бар анда. Урманнарда төрле агачлар үсә. Алар арасында наратлар, имәннәр, каеннар, чыршылар бар. Урманнарда пошилар, аю, бүре, бурсыклар очратасың. Кызыл тунлы төлкеләр, куркак куяннар да бар.
- Татарстан Республикасын «дүрт елга иле» дип йөрткәннәр. Аның аша Идел, Кама, Нократ, Агыйдел елгалары ага. Кечкенә елгалар, күлләр дә күп анда.
- Татарстанның климаты уртача. Кышлары артык салкын түгел, ә җәйләре артык эссе булмый. Бай табигате, йомшак һавасы иген үстерергә, терлек үрчетергә уңайлы. Киң болыннарында аллы-гөлле чәчәкләр, шифалы үләннәр үсә. Татарстан кырларында бодай, кукуруз, арыш, чөгендер үстерәләр. Идел һәм Кама елгалары буенда кура җиләге, чия, алма, чикләвек өлгерә.
- Чиста табигать – сәламәтлек нигезе. Шуңа күрә аны чиста тотарга кирәк. Табигатьне саклау – Ватанны саклау дигән сүз ул. *(«Ватаным Татарстан» китабыннан)*
- 1. Татарстан Республикасының табигате бик матур.
  1) туры килә 2) туры килми
- 2. Татарстанда диңгезләр дә, чүлләр дә бар.
  1) туры килә 2) туры килми
- 3. Безнең урманнарда төрле агачлар үсә.
  1) туры килә 2) туры килми
- 4. Татарстан урманнарында пальма һәм кедр агачлары үсә.
  1) туры килә 2) туры килми
- 5. Татарстан аша дүрт зур елга ага.
  1) туры килә 2) туры килми
- 6. Татарстанда артык салкын көннәр дә, бик эссе көннәр дә булмый.
  1) туры килә 2) туры килми
- 7. Үткән ел кар артык күп яуды.
  1) туры килә 2) туры килми
- 8. Киң болыннарда бодай, кукуруз, арыш үстерәләр.
  1) туры килә 2) туры килми
- 9. Идел һәм Кама елгалары буенда кура җиләге үсми.
  1) туры килә 2) туры килми
- 10. Табигатьне чиста тотарга кирәк.
  1) туры килә 2) туры килми

- **II. Напишите предложения, добавляя подходящие окончания.**
- **№**
- **Җөмләләр**
- 1.
- Без бүген цирк___ бара___.
- 2.
- Син циркка кем белән кайчан, ничә___ бара___?
- 3.
- Мин китап укы___ яратам.
- 4.
- Синең дуслар___ китапханә___ еш йөриләрме?
-
- **III. К выделенным словам поставьте вопросы.**
- **Табиб** игътибарлы булырга, авыруның серен саклый белергә тиеш. 2. Табиб һөнәре – **игелекле** һөнәр. 3. Табиблар һәрнәрсә белән **кызыксыналар**. 4. Табиблар **ярдәм итәргә** һәрвакыт әзер була. 5. Табибның эше – **авыруларның** хәлен җиңеләйтү һәм үлемнән алып калу.
-
- **IV. Составьте диалог, используя данный текст**
- **Быел Бөек Ватан сугышында җиңүгә 75 ел булды. Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булучылар арасында 93 хатын- кыз бар. Очучы Мәгубә Сыртланова санитар эскадрильяда хезмәт итә. 1942 нче елның 3 нче декабрендә беренче тапкыр дошман өстенә оча. Мәгубә Сыртланова 782 төнге очыш ясый. Ул Кырымда да, Польшада да, Көнчыгыш Пруссиядә дә , Берлин янында да дошманны утка тота. Аның сугышчан юлы Берлиннан сиксән километр ераклыкта Бруни шәһәре янында тәмамлана. Сугышта күрсәткән батырлыклар өчен Мәгубә Сыртланова Советлар Союзы Герое исеменә лаек була.**
-
-